СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш. Маннура, д.72 а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ш. Маннур ур., 72 а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР РЕШЕНИЕ

«18» сентябрь 2019 ел. № 1-45

## Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты К А Р А Р БИРӘ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Олыяз торак пунктында Тукай урамындагы, Югары Козгынчы торак пунктында Тракторчылар урамындагы , Кыраул торак пункты һәм Түбән Козгынчы торак пункты арасындагы юлларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Түбән Козгынчы авылында су башнясын һәм су алу скважинасын коймалар белән эйләндереп алу (материал сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Олыяз, Түбән Козгынчы, Кыраул,Югары Козгынчы,Дусай,Тулбай торак пунктларына янгын ранецлары сатып алу;

-Олыяз, Түбән Козгынчы, Кыраул, Югары Козгынчы, Дусай, Тулбай торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Дусай торак пунктындагы 1 Май урамына балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру ;
- Тулбай торак пунктындагы Совет урамында Боек Ватан сугышында һәлак булучылар очен һәйкәл кую.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы И.Я.Хаевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе И.Я.Хаев